ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 март, 2023 ел № 22/9

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча Шәһәр Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28, 48, 49 статьялары нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 18 апрелендәге 31/13 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2009 елның 9 апрелендәге 40/23, 2012 елның 20 сентябрендәге 21/11, 2013 елның 29 августындагы 26/15, 2015 елның 22 октябрендәге 2/19, 2016 елның 15 декабрендәге 13/11, 2018 елның 10 августындагы 26/14, 2019 елның 7 октябрендәге 33/14, 2020 елның 6 февралендәге 36/8, 2021 елның 27 маендагы 7/10 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2 пунктта «Сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы бетерелү сәбәпле муниципаль хезмәткәр белән хезмәт килешүе өзелгәндә муниципаль хезмәткәргә хезмәт законнары белән билгеләнгән оешма юкка чыгарылу яки оешма хезмәткәрләре штаты кыскартылу сәбәпле хезмәткәрләр эштән азат ителгән очракта бирелә торган гарантияләр бирелә.».

2. Шәһәр Советының 2008 елның 13 декабрендәге 36/9 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары Реестрына (Шәһәр Советының 2011 елның 14 апрелендәге 11/6, 2012 елның 20 декабрендәге 22/16, 2013 елның 29 августындагы 26/15, 2021 елның 9 декабрендәге 10/8, 2022 елның 2 ноябрендәге 17/9 номерлы Карарлары редакциясендә), «Яр Чаллы шәһәренең сайлау комиссиясе аппаратында

муниципаль хезмәт вазыйфалары» бүлеген төшереп калдырып, үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев